Татарстан Республикасы  Кама Тамагы муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

30 декабрь 2019 ел № 126

2016 елның 20 апрелендәге 19 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында" гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында” гы Федераль законга һәм 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге Советы КАРАР  ИТТЕ:

1. Келәнче авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 19 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертергә, һәм 15 статьяның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелу очракларыннан тыш, индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ формасында.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән  алынганнан соң түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:
1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Бәки авылы, Фрунзе урамы, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Келәнче

авыл җирлеге башлыгы, Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Келәнче авыл җирлеге
Советы рәисе Д.А.Кадыров